| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**10.01.2018 ел** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 16** |

2018 елга Зеленодольск муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирә торган туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарын раслау турында

2012 елның 29 декабрендәге «Мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләп чыгару тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Уставы нигезендә , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.2018 елга түбәндәгеләрне расларга:

Зеленодольск муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътыйсади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү

программаларын тормышка ашыруга , кушымта итеп бирелгән норматив чыгымнарны;

балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътыйсади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү күп профильле мәгариф оешмаларында 0,5 күләмендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын.

2.Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган, өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә, балаларга өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 пунктында расланган Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары чоры дәвамында хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карауны.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (htpp:/pravotatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – мәгариф идарәсе җитәкчесе Р.В.Афанасьевага йөкләргә.

ЗМР БК җитәкчесе вазифаларын башкаручы А.В. Старостин

Расланган
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 10 гыйнварындагы
16 номерлы карары белән

**Зеленодольск муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътсади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашуы | Бер укучыга 1 елга норматив чыгымнар, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | белем алуның беренче елы | белем алуның икенче елы | белем алуның өченче һәм аннан соң килә торган еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җирлеге | 5112 | 9467 | 11360 |
| | авыл җирлеге | 5512 | 10208 | 12249 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 5011 | 9279 | 11135 |
| | авыл җирлеге | 5411 | 10021 | 12025 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 5416 | 10029 | 12035 |
| | авыл җирлеге | 5816 | 10770 | 12924 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 5213 | 9654 | 11585 |
| | авыл җирлеге | 5613 | 10395 | 12474 |
| Экология-биология | шәһәр җирлеге | 5213 | 9654 | 11585 |
| | авыл җирлеге | 5613 | 10395 | 12474 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 5213 | 9654 | 11585 |
| | авыл җирлеге | 5613 | 10395 | 12474 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 4808 | 8904 | 10685 |
| | авыл җирлеге | 5209 | 9646 | 11575 |
| Социаль-икътыйсади | шәһәр җирлеге | 4808 | 8904 | 10685 |
| | авыл җирлеге | 5209 | 9646 | 11575 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 5213 | 9654 | 11585 |
| | авыл җирлеге | 5613 | 10395 | 12474 |